| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>СОСНОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАЛТАСИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>СОСНА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 01 » июля 2019 г. №13

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының "Сосна авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең милке турындагы мәгълүматны ачу турында Нигезләмәне раслау хакында.**

Муниципаль милекне нәтиҗәле һәм рациональ файдалану максатларында, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Сосна авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 1 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Сосна авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең милке турындагы мәгълүматны ачу турындагы Нигезләмәне расларга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы» интернет – ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә (baltasi.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә калдырам.

Сосна авыл җирлеге башлыгы: Ф.С.Габдрахманов

КУШЫМТА 1

Сосна авыл җирлеге башкарма комитеты 01 июль 2019 ел №13 карары белән расланган

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы "Сосна авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге милке турында мәгълүматны ачу турында Нигезләмә**

**1. Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы " Сосна авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге милке турында мәгълүматны ачу турында Нигезләмә «Мәгълүмат, мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүматны саклау турында» 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы, «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы, «Муниципаль сер турында» 1993 елның 21 июлендәге 5485-1 Федераль законнарына нигезләнеп эшләнде һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы "Сосна авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге муниципаль милке турында мәгълүмат составын, шулай ук аны ачу тәртибен һәм вакытын, шул исәптән аерым милек объектлары буенча, билгели.

1.2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы"Сосна авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең муниципаль милке турында мәгълүматны ачу дигәндә аның барлык кызыксынган кешеләр өчен ачык булуы күздә тотыла.

1.3. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы "Сосна авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең муниципаль милке исәбе объектлары турында мәгълүмат Россия Федерациясе норматив-хокукый актлары, Татарстан Республиксы норматив-хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Җир һәм милек мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан бирелә. Мәгълүмат бирүдән баш тарту соратып алына торган мәгълүматта дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүмат булган очракта гына мөмкин.

1.4. Юридик затларның мәнфәгатьләренә зыян китереп мәгълүмат куллану Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары белән каралган җаваплылыкка китерә.

1.5. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының "Сосна авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең муниципаль милке турында мәгълүмат Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының "Сосна авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең муниципаль милке Реестрында теркәлгән мәгълүмат, шулай ук Балтач муниципаль районы "Сосна авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге милкендә булган җир кишәрлекләре турындагы мәгълүмат күләмендә бирелә.

1.6. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы "Сосна авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең муниципаль милке турындагы

мәгълүматны ачу мәгълүмат тарату һәм кызыксынган затларга мәгълүмат бирү рәвешендә тормышка ашырыла.

Мәгълүмат тарату массакүләм мәгълүмат чараларында һәм «Интернет» челтәрендә бастырып чыгару юлы белән тормышка ашырыла.

Мәгълүмат бирү кызыксынган затларның язма мөрәҗәгатьләре буенча, шул исәптән аерым милек объектлары буенча да, тормышка ашырыла.

## 2. Мәгълүмат тарату

2.1.«Интернет» челтәрендә урнаштыру юлы белән таратыла торган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы "Сосна авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең милке турында мәгълүмат түбәндәге мәгълүмат исемлеге (әлеге мәгълүмат закон тарафыннан тарату тыелган мәгълүматны үз эченә алган очраклардан тыш) билгеләнә:

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы "Сосна авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең муниципаль учреждениеләр исемлеге (исеме, урнашу урыны);

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы "Сосна авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең унитар предприятиеләр исемлеге (исеме, урнашу урыны);

устав капиталы өлеше (акцияләр пакеты) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы "Сосна авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең милкендә булган хуҗалык ширкәтләре исемлеге (исеме, хуҗалык ширкәте урнашу урыны, устав капиталында Балтач муниципаль районы өлеше);

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы "Сосна авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең милкендә булган күчемсез милек (биналар, тораклар) исемлеге (исеме, урнашу урыны, мәйданы, куллану максаты, куллану чикләүләре, өченче затлар хокукы белән чикләүләр);

Татарстан Республикасы Балтач муниципальрайоны "Сосна авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең муниципаль милкен хосусыйлаштыруны фаразлау планы (программасы);

Татарстан Республикасы Балтач муниципальрайоны "Сосна авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең муниципаль милкен хосусыйлаштыруны фаразлау планын (программасын) башкару турында хисап.

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы "Сосна авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең муниципаль милке турында әлеге мәгълүмат массакүләм мәгълүмат чараларында да бастырыла ала.

2.2. Әлеге карарның 2.1 пунктында күрсәтелгән мәгълүмат квартал саен хисап вакытыннан соң килүче айның 10 числосына кадәр Балтач муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

2.3. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы "Сосна авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең муниципаль милкендә булган мөлкәт объектлары турында мәгълүматны аларны хосусыйлаштыру белән бәйле рәвештә тарату хосусыйлаштыру турында закон белән билгеләнгән күләмдә башкарыла.

## 3. Кызыксынган затларга мәгълүмат бирү

3.1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы "Сосна авыл

җирлеге» муниципаль берәмлегенең муниципаль милке Реестрында теркәлгән аерым милек объектлары (алга таба - исәп объектлары) буенча мәгълүмат кызыксынган затлар мөрәҗәгате буенча хат яки Татарстан Республиксы Балтач муниципаль районы "Сосна авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең муниципаль милке Реестрыннан өземтә рәвешендә бирелә.

3.2. Исәп объектлары буенча мәгълүмат (яки мәгълүмат бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән карар) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Җир һәм милек мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан мөрәҗәгатьне теркәгәннән соң 30 көннән дә соңга калмыйча бирелә.

3.3. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы "Сосна авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең муниципаль милке Реестрыннан өземтәләр бирелә:

исәп объектының хокукый ияләренә яки аларның законлы вәкилләренә;

исәп объектының хокукый иясеннән яки аның законлы вәкиленнән ышаныч кәгазе алган физик яки юридик затларга;

Россия Федерациясе Хисап палатасына, Татарстан Республикасы Хисап палатасына, Балтач муниципаль районы контроль-хисап палатасына;

Татарстан Республикасы, Россия Федерациясенең башка субъектлары җирле үзидарә органнарына һәм дәүләт хакимияте органнарына;

дәүләт хакимиятенең федераль органнарына, шул исәптән:

күчемсез милеккә хокук барлыкка килүгә дәүләт теркәве үткәрүче һәм аның белән сделкалар башкаручы органнарга;

салым органнарына;

производствода исәп объектлары һәм (яки) аларның хокукый ияләре белән бәйле эшләр булган очракларда суд, хокук саклау органнарына, суд приставы-башкаручыларына, федераль монополиягә каршы органга һәм аның Татарстан Республикасындагы территориаль органына.

3.4. Әлеге Нигезләмәнең 3.3. пунктында күрсәтелмәгән кызыксынган затларга исәп объектларының Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы "Сосна авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең муниципаль милке Реестрында булуы турындагы мәгълүмат кына бирелә.

3.5. Язма рәвештә бирелә торган соратып алынган мәгълүмат бирүдән баш тарту дәлилләнгән булырга тиеш. Соратып алынган мәгълүматны бирүдән баш тарту өчен нигез булып түбәндәге сәбәпләр тора:

мөрәҗәгатьтә закон тарафыннан чикләнгән мәгълүмат соратып алыну; мөрәҗәгатьнең эчтәлеге буенча әлеге затны кызыксындырган объектны билгеләү мөмкин булмау;

мөрәҗәгатьтә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы" Смәел авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең муниципаль милке Реестрында булмаган исәп объекты күрсәтелү.